# Ислам нуры

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№17 (741) 16 сентябрь 2021 ел (1443, сәфәр) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга


***2021 ел - Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы***

## ҖЫЛЫ СҮЗ ҖАН АЗЫГЫ



Мөгамәләләрдә әдәпле вә сак булу холкың ризалыгына сәбәп булганы хәлдә, һичбер акча сарыфына да ихтыяр булмаячактыр. Мөгамәлә әгәр дә әдәпле булса — иң мөшкел максатлар хасил булыр, бикле ишекләр ачылыр, йомшак сүзләр күңелләрне рәхәтләндерер, ихлас сүз олы бүләкләрдәй артык шатлык китерер, ачык йөз вә катлаусызлык, дуслык вә мәхәббәткә дәлил булыр. Шуның өчен теләсә кем булсагыз булыгыз, адәм балалары белән әдәпле мөгамәлә итегез. Йомшак вә мөлаем сүзле, ихласлы булыгыз! Күңелсез яки ачулы вакытыгызда халык белән сөйләшмичә, бәлки ачу-кызуы сүрелгәнгә кадәр сабыр итегез, адәмнәрнең кимчелекләрен гафу итегез, һәр эштә фикерле вә игътибарлы булыгыз, бу исә — тәрбияле булу билгеседер. Адәмнәргә катнашмыйча бер читтә тормагыз вә яки кем очрады исә аңа катышып, дуслык күрсәтмәгез, бәлки һәр эштә гаделлек белән хөр фикерле, дөрес сүзле, баһадир, эчегез вә тышыгыз бер рәвешле булыгыз! Кешеләрнең усал мөгамәләләренә каршы яхшылык итегез вә яхшы мөгамәләләренә каршы тагын да артык яхшылык итегез, башкаларга күрсәтәчәк мөгамәләгез — алардан күрергә теләгән мөгамәләләрдән һәрхәлдә артык дәрәҗәдә булуына игътибар итегез! Халыктан күркәм мөгамәлә күрергә өметегез булса, үзегез дә аларга яхшы мөгамәлә күрсәтегез. Алардан хөрмәт күрергә теләсәгез, үзегез дә аларга хөрмәт күрсәтегез.

**Риза ФӘХРЕДДИН** *(”Әхлак гыйлеме”ннән)*

## ТӨЗЕЛЕШ ГӨРЛИ

1 сентябрь көнне Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәрип улы Шәймиев Чаллының “Җәмигъ” мәчете төзелешен карарга килде. Әлеге чарада шәһәр мэры Наил Гамбәр улы Мәһдиев, Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин, “Җәмигъ” мәчете төзелеше фонды” директоры Уел Галим улы Хөсәенов һәм мәчет төзелешендә үз көчләрен керткән шәхесләр катнашты. Минтимер Шәрип улы мәчет төзелеше белән танышканнан соң эшләрнең барышы белән канәгать калды һәм төзүчеләргә рәхмәтләрен белдерде.



Алла боерса, «Җәмигъ» мәчете Чаллының истәлекле урынына әйләнергә тиеш. Ул берьюлы 3 мең кешене сыйдыра алуы белән үзенчәлекле булачак. Мәчет каршындагы мәйданда бәйрәмнәр вакытында берничә мең кеше гыйбадәт кыла алачак.

Аллаһ йорты ачылганнан соң шәһәр мөхтәсибәте «Җәмигъ» мәчетенә күченергә ниятли, моның өчен гыйбадәтханәдә проект нигезендә видеоконференцияләр үткәрү өчен зал да каралган. Биредә шулай ук ислам музее, никахлашу залы һәм уку бүлмәләре дә булыр дип көтелә.

2007 елда «Җәмигъ» мәчете төзелешенә финанс ярдәм фонды оеша. Ул проектка акча җәлеп итү белән шөгыльләнә. Иганә акчалары төрлечә килә. Өлкән яшьтәге мөселманнар мәчет төзелешенә үз пенсияләрен бирә, шәһәрдә билгеле булган эшмәкәрләрдән акчалар килә, хәтта мәчет төзелешендә эшләүче төзүчеләр дә эшләрнең бер өлешен бушка башкара. Хәзер мәчет төзелеше өчен акча бирү җиңелләшкән. Акчаларны штрих-код кулланып күчереп була. Яки искечә: «Җәмигъ» мәчете төзелеше Ярдәм фондының исәп-хисап счетына күчерергә мөмкин.

*«Җәмигъ мәчете» комплексы төзелешенә финанс ярдәм фондының юридик адресы (урнашкан урыны): 423800, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23, Мәчет.*

## ТР МДН ХӘБӘР ИТӘ

Сәфәр аеның 4 нче көнендә Әлмәт мөхтәсибәтендә Ризаэтдин Фәхреддин исемендәге мәчет кубогына мөселманнар арасында мини-футбол буенча Республикакүләм турнир узды. Әлеге чара Идел буе Болгар дәүләтендә Исламны кабул итүнең 1100 еллыгына багышланды. Турнирда барлыгы 18 команда катнашты. Катнашучылар Әлмәт, Алабуга, Бөгелмә, Кукмара, Лениногорск, Зәй, Түбән Кама, Арча, Мөслим, Саба, Азнакай, Чирмешән, Спас, Әгерҗе районнарыннан, Чаллы шәһәреннән, Чувашия Республикасының Шыгырдан авылыннан килде. Командалар 4 төркемгә бүленеп көч сынашты һәм төркемнән җиңүче ачыкланды. Бүләкләү тантанасында Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов катнашты.

Дүрт җиңүче команда плей-оффта катнашты. Беренче урынга – Бөгелмә шәһәре, икенче урынга – Кама Аланы бистәсе, өченче урынга – Әлмәт шәһәре, дүртенче урынга – Саба районы командалары чыкты. Аларга акчалата бүләкләр, кубоклар, грамоталар, медальләр тапшырылды.

***




Сәфәр аеның 4 нче көнендә Бөгелмәдә “Милли моң” Россиякүләм мөнәҗәтләр фестивале үтте. Бәйгене оештыручылар булып Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте, Бөгелмә шәһәре һәм Бөгелмә районы мөхтәсибәте, Бөгелмә шәһәренең Татар мәдәнияте үзәге тора. Быел фестиваль, Идел буе Болгар дәүләтендә Исламны кабул итүнең 1100 еллыгына багышланып, Татарстанда игълан ителгән Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында узды.

Фестиваль традицион рәвештә Коръән аятьләре уку белән башланып китте. Россиякүләм мөнәҗәтләр фестивалендә катнашучыларга Татарстан мөфтие исеменнән Татарстан Республикасы мөфтиенең беренче урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов мөрәҗәгать итте. Аннан соң ул Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның рәхмәт хатларын тапшырды. Бу көнне Татар мәдәнияте үзәге залында 200гә якын талантлы мөнәҗәт башкаручылар җыелды. Шунысын билгеләп үтәргә кирәк: фестивальнең географиясе киңәйгәннән-киңәя: быел мөнәҗәт башкару осталыгын Ульяновск, Оренбург, Сахалин, Чистай, Лениногорск, Яр Чаллы, Әлмәт һ.б. башкаручылары күрсәтте. Аларның иҗади чыгышларын мәртәбәле жюри бәяләде.

# ДИНДӘ БЕРДӘМЛЕК

**Аллаһы (Сөбханәһү вә Тәгалә) Коръәни-Кәримдә әйтә: 2.30. «Һәм Раббың фәрештәләргә әйтте: «Мин, әлбәттә, җир өстендә хәлифә итеп Адәмне кылачакмын».** Адәмне һәм Адәмнең нәселен Аллаһы Тәгалә җир өстенә хәлифә итеп билгеле. Кеше хәлифә буларак җир йөзендә Аллаһы Тәгаләнең кануннарының үтәлүен тәэмин итәргә тиеш. Бу – бөтен кешегә дә йөкләтелгән бурыч, бөтен кешенең дә үтәргә тиеш булган вазыйфасы. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: «Сезнең һәрберегез көтүче һәм һәрберегез үзенең көтүе хакында соралырсыз». Һәркем үзенең дөньядагы дәрәҗәсенә карап, үз урынында хәлифә. Һәркем үзенең җәмгыятьтә тоткан урынына, дәрәҗәсенә карап бу вазыйфаны тиешенчә алып барырга тиеш. Кул астында эшләүчеләргә карап аларның җитәкчеләре туры юлга керергә мөмкин, җитәкчеләренә карап кул астындагылар туры юлга керергә мөмкиннәр. Байлык белән дә шулай ук: кемдер байлыгы күп булу сәбәпле диндә булырга мөмкин, ә кемдер исә байлыгы булмау сәбәпле диндә булырга мөмкин. Шуңа күрә дә кешенең Аллаһ каршындагы дәрәҗәсе аның дөньяда тоткан дәрәҗәсе, байлыгы белән билгеләнми, бәлки Аллаһыга булган мөнәсәбәте, тәкъвалыгы белән билгеләнә.

***Аллаһы (Сөбханәһү вә Тәгалә) әйтә: «Ий кешеләр, Без сезне ир һәм хатын итеп халык кылдык, һәм сездән тармаклар вә кабиләләр кылдык, бер-берегезне аерып танымаклыгыгыз өчен, тәхкыйк, сезнең Аллаһы хозурында хөрмәтлеләрегез Аллаһыдан куркып гөнаһлардан саклanучыларыгыздыр, Аллаһы белүче, һәм һәр эшегездән хәбәрдар».***

Аллаһы (Сөбханәһү вә Тәгалә) әйтә: 49.13. «Ий кешеләр, Без сезне ир һәм хатын итеп халык кылдык, һәм сездән тармаклар вә кабиләләр кылдык, бер-берегезне аерып танымаклыгыгыз өчен, тәхкыйк, сезнең Аллаһы хозурында хөрмәтлеләрегез Аллаһыдан куркып гөнаһлардан сакланучыларыгыздыр, Аллаһы белүче, һәм һәр эшегездән хәбәрдар».

Тәкъва кеше башка кешенең кимчелеген тикшерми, ул турыда аның кайгысы юк. Ул үзе турында, үзенең гыйбадәте, үзенең дине турында ныграк кайгырта. Чөнки бу фетнәләр заманында һәркемгә үзе турында, үзенең дине турында кайгыртуы хәерлерәктер. Югыйсә, бүген кайберәүләрнең дине башкаларның гыйбадәтен, гакыйдәсен тикшерүгә кайтып кала. Күпчелек кеше мәчеткә атнага бер генә, фәкать җомга көнне генә килә. Көннәрнең олугысы булган җомга көнне бөтен мөселманнарга да җомга намазы уку фарыз кылынды. Җомга намазы төрле фикердәге, төрле караштагы, хәтта үзара дошманлыкта булган мөселманнарның бергә җыелуына бер зур сәбәп булып тора. Җомга намазы һәркем өчен фарыз. Имам сиңа ошыймы-ошамыймы, җомгага син яраткан кешеләр киләме, яисә син яратмаган кешеләр киләме, син, гозерең булмаса, үз мәхәлләңдәге мәчеткә җомга намазына килергә тиешсең. Тәкъва мөэминнәр үзләренең бөтен үпкәләрен, бер-берсенә булган нәфрәтләрен, ачуларын читкә куеп, Раббылары йөкләгән бурычларын үтәргә дип мәчетләргә җомга намазы укырга киләләр. Алар фәкать шушы сәбәп белән генә киләләр. Диннән уен ясаучылар, диндә үзләрен зур галим санап тәкәбберләнүчеләр җомга намазын сәбәп итеп үзләренең фикерләрен таратырга, үзләре артыннан кеше ияртергә, фикердәшләр тупларга дип мәчетләргә киләләр һәм килгәч тә Аллаһыны зикер итәсе урында, белер-белмәс гыйлемнәрен, кемнәндер нәрсәдер ишеткәннәрен сөйләп, башкаларның гаепләрен, кимчелекләрен тикшереп вакытларын уздыралар, хәтта ул кимчелекләр, күпчелек очракта, кимчелек тә булмыйча, фәкать шул сөйләп йөрүчегә ошамаган нәрсәләр генә булалар.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: «Һәр гамәл ниятенә карап бәяләнә…» .

Намаз укырга килүчеләр намаз укулары белән бәяләнсә, башка ният белән килүчеләр дә шул ниятләренә күрә бәяләнерләр. Алар Аллаһының боерыкларын үтисе урында, үзләренең фикерләрен башкаларга тагып, үзләрен генә хак дип, башкаларны батыл, ялган дип тәкәбберләнеп йөрүчеләр. Бүтәнчә ничек әйтәсең? Ел саен һәр мәчеттә 1 октябрьдә якшәмбе мәктәбенә укучылар җыялар, аннары кыш буе аларга Ислам дине нигезләрен, Коръән һәм намаз уку тәртипләрен өйрәтәләр. Ә «Ак мәчет»тә өстәмә рәвештә 1 февральдә дә төркемнәр җыела. Бу якшәмбе мәктәпләрендә халыкка башлангыч дини белем бирелә һәм Коръән укырга өйрәтелә. Кайчак «монда дөрес өйрәтмиләр, монда йөрмәгез», дип, вәсвәсә кылып йөрүчеләр дә очрый. Мәчеткә килгәннәрнең иманнары бар инде, алар өчен кайгырырга кирәк түгел, ялгышсалар да күпкә ялгышмаслар, ә менә шәһәр, ил динсезләр белән тулы, шуларны туры юлга кертергә кирәк. Без халыкны ничек мәчеткә җыярга белмибез, ә алар кешене мәчеттән куалар. Мәчеткә килгән кешеләрне укытырга безнең мөгаллимнәребез бар. Мәчет-мәдрәсәләр белән, андагы уку-укыту тәртипләре белән риза булмаган кешеләргә очсыз-кырыйсыз Рәсәй бар, бик күп авылларда хәтта мәчет тә юк, туйганчы үз фикерләрен шунда таратсыннар. Мәчет-мәдрәсәләрнең имамнарын, мөгаллимнәрен санга сукмау – бу тәкәбберлек түгелме?

Әмма онытырга кирәк түгел, тәкәбберләрнең урыннары җәһәннәмдә. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: «Күңелендә тузан бөртеге кадәрле генә тәкәбберлек булган кеше җәннәткә кермәс»

Җир шарында бүген бер млрд ярым мөселман исәпләнә. Бу бер млрд ярымга сөнниләр дә, шигыйлар да, мәзһәб әһелләре дә, мәзһәбсезләр дә, вахаббийлар да, суфийлар да һәм әйтелми калган бик күп фиркалар, хәтта үзен мөселман санаган, фарызны үтәми, хәрамнан сакланмый торганнар барысы да керә. Аларның һәрберсе үзен генә хак дип саный. Шулай булмаса төркемнәргә бүленү булмас иде. Төркемнәргә бүленү бездән тормый. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: «…Кулында Мөхәммәднең җаны булган зат белән ант итәм, минем өммәтем 73 төркемгә бүленерләр, әмма шуларның берсе генә җәннәткә һәм 72 төркеме җәһәннәмгә керер». Сорадылар: «Кемнәр ул җәннәткә керүчеләр?» Ул әйтте: «Җәмәгать белән булучылар», диде» .

Нигәдер кайберәүләр үзләрен генә шул җәннәткә керә торган төркемнән, калганнарны җәһәннәмгә керә торган дип саныйлар һәм бөтен шөгыльләре калганнарны да үзләренең төркемнәренә кертү. Әгәр дә бер генә төркем була торган булса, пәйгамбәребез (с.г.в.) «мөселманнар 73 төркемгә бүленерләр», дип кисәтмәс иде.

Башкаларны үзенә ияртү нияте кешене төп максаттан читкә юнәлдерә. Аның максаты дин тарату булмыйча, үз фикерен таратуга әйләнә. Кеше хәлифә дигән сүзнең асыл мәгънәсен аңламыйча, үзен ил белән, халыклар белән идарә итә торган хәлифә итеп сизә башлый һәм хәлифәт төзергә керешә. Яхшылыкка өндисе урында, фетнә таратуга, үзенә ияргән күп кенә мөселманнарның бәлагә юлыгуына сәбәп була. Ә бит Аллаһы Тәгалә Мөхәммәд (с.г.в.) өммәтен хәерле эшләргә өндәүләре һәм бозык эшләрдән тыюлары сәбәпле генә иң хәерле өммәт дип атады. Аллаһы (Сөбханәһү вә Тәгалә) әйтә: 3.110. «Әй Мөхәммәд өммәте, сез дөньяга чыгарылган өммәтләрнең иң хәерлесе булдыгыз, кешеләрне хәерле эшләргә, хәерле гамәлләргә өнди белү белән өндәдегез һәм бозык, зарарлы эшләрдән тыя белү белән тыйдыгыз һәм Аллаһыга хак ышану белән ышандыгыз».

*(Ахыры газетаның киләсе санында)*

**Рөстәм хәзрәт ШӘЙХЕВӘЛИЕВ,**
*Чаллының “Ак мәчет” имам-хатыйбы*

## САЛАВАТ УКУНЫҢ ФАЙДАСЫ

Аллаһы Тәгалә Изге Коръәндә әйтә: **“Аллаһ һәм фәрештәләре, дөрестән дә, Пәйгамбәргә салават әйтәләрдер. Әй иман китергәннәр! Сез дә инде Пәйгамбәргә салават китерегез, сәламнәр күндерегез!”** *(Әхзаб/Гаскәрләр”, 33:56)*

Расүлүллаһ (с.г.в.) әйткән: “Кем (бер тапкыр) салават әйтсә, Аллаһ аңа моның өчен ун кат рәхмәтен бирер”. *(Имам Мөслим, “Саләт”, 70; имам Тирмизи, “Витр”, 21)*

“(Бүтәннәрдән) ешрак салават әйткән ***(Пәйгамбәребезнең исемен һәр әйткән саен “Салләлаһү галәйһи вә сәллам” дип өстәү)*** кешеләр Ахирәт көнендә миңа башкалардан якынрак булыр”. *(Имам Тирмизи, “Витр”, 21)*

Хакыйкатьтә, җомга көне - иң хәерле көннәрегездән берседер, шулай булгач, бу көндә миңа ешрак салават китерегез, чөнки салаватларыгыз миңа китерелеп күрсәтелер”. Кешеләр сорадылар: “Әй, Аллаһның Расүле, ничек итеп без кылган салаватлар үзеңә китерелеп күрсәтелер, син инде туфракка әйләнгәч,” - (шуннан соң) Пәйгамбәр (с.г.в.) әйтте: “Хактыр ки, иң кодрәтле һәм бөек булган Аллаһ пәйгамбәрләрнең җәсәден җир өчен хәрам кылды”. *(Имам Әбү Давыт, “Витр”, 26; имам Ибне Мәҗәһ, “Икамәт”, 79).*

“Аның янында мине искә алган чагында салават китермәгән кешене түбәнсетелү көтсен!” *(Имам Тирмизи, “Дәгъват”, 101)*

“Әлеге салаватны гомерендә 1 тапкыр, яки айда 1 тапкыр, яки атнада бер тапкыр, җомга көнендә укыган кеше Аллаһ Тәгалә үзен җәннәткә кертер дип өмет итә аладыр”.

*(“Ислам дине нигезләре”ннән)*

# ГОШЕР БИРҮ

**Бакча уңышы җыеп алынды диярлек. Уңышның уннан бер өлешен мохтаҗларга бирергә кирәклеген бөтенебез дә белеп бетерми. Ислам динендә ул гошер сәдакасы дип атала. Гошер – җирдән җыеп алынган уңышның зәкяте.**

**Мөселман кешесе бакчадан җыеп алган уңышының уннан берен сәдака итеп бирергә тиеш. Казанның Әмәт бистәсе мәчете имам-хатыйбы Равил хәзрәт БИКБАЕВ әйтүенчә, гошер сәдакасын бирергә кирәклеге Коръәндә дә искә алына.**

– «Сыер» сүрәсенең 267нче аятендә: «И мөэминнәр! Кәсеп итеп тапкан малларыгыздан һәм Без сезнең өчен җирдән чыгарган уңышлардан яхшысын Аллаһы күрсәткән урыннарга бирегез!..» – диелә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) дә бер хәдисендә: «Җыеп алынган уңышның яңгыр һәм елга сулары белән үстерелгән өлешеннән – уннан берен, ә хезмәт куеп, ташылып су сибеп үстерелгән өлешеннән егермедән бер өлеше сәдака итеп бирелергә тиеш», – дигән. Моннан чыгып караганда, 100 чиләк бәрәңге алгансыз икән, аның 10 чиләген гошер сәдакасы итеп бирергә тиешсез. Гошер сәдакасы биргәннән генә кеше ач калмый. Киресенчә, Аллаһы Тәгалә сиңа аны икеләтә кайтара. Гошер сәдакасын киләсе елга мул итеп уңыш алу өчен дә бирергә кирәк. Ул малга бәрәкәт бирә.

Үзем карап, су сибеп үстердем, диючеләр дә бар. Бу ялгыш фикер: бакчада үстергән җимеш, яшелчәләребезнең мул булып үсүендә Аллаһы Тәгаләнең дә рәхмәте бар. Һәр әйбернең хакыйкый сәбәбе булып Аллаһының рәхмәте тора. Ул насыйп итсә була, итмәсә – юк. Насыйп ризык тешне сындырып керә, дип тә әйтәләр бит бездә. Үз бакчабызда үзебезнең хәләл көчебез белән үстергән булсак та, хезмәт җимешләребезне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән үстерә алганлыгыбызны да онытып җибәрмик.

Гошерне мохтаҗ кешеләргә, ятимнәргә, ялгыз кешеләргә, мәдрәсә шәкертләренә бирү дөрес санала. Аны бирүнең төгәл вакыты юк. Гадәттә, уңышны җыеп алгач бирәләр. Сакларга урыны булмаганнар шулай итә. Соңрак та ярый.

**– Балдан да гошер бирергәме?**

– Әбү Хәнифә мәзхәбендә балның да гошере бар. Аның да уннан бер өлеше гошер була. Йөз килограмм бал алсаң, шуның ун килограммын сәдака итеп бирергә кирәк.

**– Гошер сәдакасын бирмәсәң гөнаһлы буласыңмы?**

– Әйткәнемчә, ул зәкятнең бер төре. Мөмкинлегең була торып бирмәү – гөнаһ. «Ибраһим» сүрәсенең 7нче аятендә Ул: «Мин биргән нигъмәтләргә шөкрана кылсагыз, арттырып бирермен. Әгәр биргән нигъмәтләремә шөкрана кылмасагыз, газабым каты булыр», – дигән. Бу урында мин фермерлар, колхоз, инвесторлар, күмәк хуҗалыкларны да гошер бирергә чакырыр идем. Алар бодаен да, кукуруз, рапс, көнбагышын да утырта. Гошер ул бәрәңге генә дигән сүз түгел. Әбү Хәнифә мәзхәбендә, җирдә үскән бөтен әйбердән гошер бирелә, фәкать утын белән камыш кебек нәрсәләрдән генә гошер чыгарылмый.

**– Тиешле гошерне бирмәсәң, Аллаһы Тәгалә яңгырын вакытында бирмәс, ди. Бу чынлап та шулаймы?**

– Андый хәдис дөрестән дә бар. Яуган яңгырда хайваннар өлеше генә булыр, ягъни хайваннар булмаса, аны да яудырмас иде.

*Әңгәмәдәш* – **Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА**
*(”Шәһри Казан”)*

# АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘ КЕМНӘРНЕ ЯРАТА?

Барча галәмнәрнең, бу дөнья һәм ахирәтнең хуҗасы Раббыбыз Аллаһы Тәгалә кешене яратса, бу, әлбәттә, аның өчен бик зур дәрәҗә генә түгел, олуг бәхет тә була, чөнки Аллаһның кешедән риза булуы ул – һәр кеше тормышының төп максаты. “Аллаһы Тәгалә мине яратамы?” – дигән сорауга җавапны кеше кайбер галәмәтләргә игътибар итеп белә ала. Галимнәребез билгеләп үткәнчә, бөек Яратучыбызның кешегә мәхәббәт белән карауның шундый аерым галәмәтләре бар:

1. Аллаһы Тәгалә кешене яратса, аны дин юлына бастырып, туры юлга кертә һәм аңа дин мәсьәләләрен яхшы һәм дөрес аңлау мөмкинлеген бирә.

2. Аллаһы Тәгалә кешене яратса, ул кеше намаз, ураза, сәдака кебек гыйбадәтләрне кылудан, шулай ук Коръән укудан, башкаларга ярдәм итүдән, гомумән, изге-игелекле гамәлләр эшләүдән тәм таба, рухи рәхәтлек кичерә.

3. Аллаһы Тәгалә кешене яратса, аның күңеленә барлык начар, кабахәт сүз-гамәлләргә нәфрәт урнаштыра. Аллаһы Тәгалә тыйган нәрсәләрнең кешегә фәкать зыян гына китергәнен тормыш үзе раслады (күпләр моны соң булса да аңлый). Шуңа күрә Аллаһы Тәгалә үзенең яраткан бәндәсен гөнаһлардан саклый.

4. Аллаһы Тәгалә кешене яратса, аның холкын яхшы итә, андый кешегә мәрхәмәтлелек хас була, ул башкаларны ярата, аларның кимчелекләрен гафу итә, аларга ярдәм итәргә тырыша, якыннарының гына түгел, чит кешеләрнең кайгысына да битараф булмый, нидер эшли алмаса да, һичьюгында сүз белән хәлләрен җиңеләйтергә омтыла, алар өчен дога кыла.

5. Аллаһы Тәгалә кешене яратса, аңа авырлыклар һәм сынаулар бирә. Күпләр авыр хәлгә төшүне, якын кешеләрне югалтуны, авырып китүне һәм башка проблемаларны бәхетсезлек дип кабул итә. Әмма күңелсез, фаҗигале хәлләр дә Аллаһның игътибары, хикмәтле сынавы һәм нәтиҗә буларак, яратуының бер билгесе дә булырга мөмкин. Бер мөбарәк хәдистә бу хакта болай диелә: “Иң зур савап сынаулар белән килә. Аллаһы Тәгалә кемнедер яратса, аны сыный, һәм авырлыкны сабырлык белән кабул итүче кеше Аллаһның ризалыгын ала, зарланса – Аның ачуына дучар була”.

6. Аллаһы Тәгалә кешене яратса, ул хаталанган яки ниндидер гөнаһ кылган очракта җәзасын тиз бирә яисә аны төшендә кисәтә. Шул сәбәпле кеше хатасын аңлый, гөнаһлы гамәлен кылудан туктап, тәүбә итә.

7. Аллаһы Тәгалә кешене яратса, аның ахыргы гамәле хәерле була, ягъни җан биреп ахирәткә күчәр алдыннан ул кеше ниндидер изгелек кыла яки тәһарәтле килеш (әйтик, намаз укыганнан соң) вафат була.

**Ришат хәзрәт КУРАМШИН** әзерләде

# АЛЛАҺНЫҢ 99 ИСЕМЕН ЗЕКЕР ИТҮНЕҢ ФАЗЫЙЛӘТЛӘРЕ

**Йәә Мәлик** – Мәлик исеме хөкемдар дигән мәгънәне үз эченә алган. Әлеге исемне теленнән өзмичә күп укыган кеше беркемгә мохтаҗ булмаган хәлдә гомер итәр.

**Йәә Котдуус** – Котдус исеме кимчелекләрдән пакъ булучы дигән мәгънәне үз эченә алган. Әлеге исемнең мәгънәсен күз алдында тотып, көн дә 100 тапкыр укырга тырышкан кеше, Аллаһның рәхмәте белән, әкренләп кимчелекләреннән арыныр.

**Йәә Сәләәм** – Сәләәәм исеме тынычлык һәм татулык дигән мәгънәне үз эченә алган. Әлеге исемне һәрдаим укырга тырышкан кешене Аллаһы Тәгалә үз сакчыллыгы астына алыр. Шулай ук бу исемне 115 яки 160 тапкыр укып, суга өреп, суын эчкән кеше, Аллаһның ярдәме белән, авыруга каршы җиңеллек табар.

**Йәә Мөэмин** - Мөэмин исеме тугрылык һәм иминлек иясе дигән мәгънәне үз эченә алган. Дошманнардан һәм төрле куркыныч хәлләрдән котылыр өчен 630 тапкыр укыган кеше үзенең теләгенә ирешер.

**Йәә Муһәймин** - Муһәймин исеме яклаучы һәм саклаучы дигән мәгънәне үз эченә алган. Госел алганнан соң, ихлас күңел белән, ике рәкагәть намаз укып, әлеге исемне 100 тапкыр укыган кеше тән һәм җан чисталыгына ирешер.

***СОРАУ-ҖАВАП***

**Сорау.** Әссәламүгаләйкүм! Шәригатьтә ир-атларга хатын-кызларга охшашлану тыелган. Заманча аяк киемнәренә карата караш нинди икән? Чөнки бүгенге көндә кедалар, кроссовкалар киеп йөриләр. Мондый аяк киемнәрен кияргә рөхсәт бармы?

**Җавап.** Вәгаләйкүм әссәлам! Бар. Мондый аяк киемнәрен кияргә ярый. Бу очракта аерым бер очрак түгел, ә гадәт әһәмиятлерәк роль уйный. Ислам фикһының нигез принципларының берсе түбәндәгечә яңгырый: “Гадәт хөкем чыгарганда исәпкә алына” (“Әшбәх үәән-нәзаир”, 6 нчы кагыйдә, “Мәҗәллә”, 36 бит).

Шуны истә тотарга кирәк, бу кагыйдәнең шартлары һәм чикләүләре бар, шуңа күрә бу кагыйдәне куллануның барлык шартларын да белмәгән кеше аны мөстәкыйль рәвештә куллана алмый.

Шулай итеп, хатын-кыз өчен булган аяк киемен хатын-кызлар, ирләр өчен махсус тегелгәнен ирләр кияргә тиеш. Икесе өчен дә уртак (унисекс) булган аяк киемнәрен дә кияргә ярый, әмма кием бик тә ирләрнекенә охшаган икән, аны кимәү хәерлерәк, яисә, киресенчә, кием хатын-кызныкына бик охшаган икән, аны ирләргә кимәү хәерлерәк. Киемнең мөселманнар яшәгән җирлеккә туры килүенә игътибар итү дә бик мөһим.

Ә Аллаһ – яхшырак белүче!

*(Диния нәзарәте фәтваларыннан)*

# Октябрь аена намаз вакытлары

| Милади октябрь | Көн исеме | Сафәр, рабигуль-әүвәл | Иртәнге намаз | | | | | | Кояш чыга | | | Зәвәл | | | Өйлә | | | Икенде | | | Ахшам | | | Ясту | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Таң беленә | | | Мәчетләрдә укыла | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан |
| 1 | Жм | 24 | 05:18 | 03:28 | 03:41 | 05:50 | 04:03 | 04:16 | 07:18 | 05:33 | 05:46 | 13:06 | 11:20 | 11:33 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:07 | 15:05 | 15:18 | 18:52 | 17:05 | 17:18 | 20:22 | 18:47 | 19:00 |
| 2 | Шм | 25 | 05:20 | 03:30 | 03:43 | 05:52 | 04:04 | 04:18 | 07:20 | 05:34 | 05:48 | 13:05 | 11:19 | 11:32 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:05 | 15:03 | 15:16 | 18:50 | 17:03 | 17:16 | 20:20 | 18:44 | 18:57 |
| 3 | Як | 26 | 05:22 | 03:32 | 03:45 | 05:54 | 04:06 | 04:20 | 07:22 | 05:36 | 05:50 | 13:05 | 11:19 | 11:32 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:03 | 15:01 | 15:14 | 18:47 | 17:00 | 17:13 | 20:17 | 18:41 | 18:55 |
| 4 | Дш | 27 | 05:24 | 03:35 | 03:48 | 05:56 | 04:08 | 04:22 | 07:24 | 05:38 | 05:52 | 13:05 | 11:19 | 11:32 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:01 | 14:58 | 15:11 | 18:45 | 16:58 | 17:11 | 20:15 | 18:39 | 18:52 |
| 5 | Сш | 28 | 05:26 | 03:37 | 03:50 | 05:58 | 04:10 | 04:24 | 07:26 | 05:40 | 05:54 | 13:05 | 11:18 | 11:31 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 15:59 | 14:56 | 15:09 | 18:42 | 16:55 | 17:08 | 20:12 | 18:36 | 18:49 |
| 6 | Чш | 29 | 05:28 | 03:39 | 03:52 | 06:00 | 04:12 | 04:26 | 07:28 | 05:42 | 05:56 | 13:04 | 11:18 | 11:31 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 15:57 | 14:54 | 15:07 | 18:40 | 16:53 | 17:06 | 20:10 | 18:33 | 18:47 |
| 7 | Пж | 1 | 05:30 | 03:41 | 03:54 | 06:02 | 04:14 | 04:28 | 07:30 | 05:44 | 05:58 | 13:04 | 11:18 | 11:31 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 15:55 | 14:51 | 15:04 | 18:37 | 16:50 | 17:03 | 20:07 | 18:31 | 18:44 |
| 8 | Жм | 2 | 05:32 | 03:43 | 03:56 | 06:04 | 04:16 | 04:30 | 07:32 | 05:46 | 06:00 | 13:04 | 11:17 | 11:31 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 15:53 | 14:49 | 15:02 | 18:35 | 16:47 | 17:00 | 20:05 | 18:28 | 18:41 |
| 9 | Шм | 3 | 05:34 | 03:45 | 03:58 | 06:06 | 04:18 | 04:32 | 07:34 | 05:48 | 06:02 | 13:03 | 11:17 | 11:30 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 15:52 | 14:47 | 15:00 | 18:32 | 16:45 | 16:58 | 20:02 | 18:26 | 18:39 |
| 10 | Як | 4 | 05:35 | 03:47 | 04:00 | 06:07 | 04:20 | 04:34 | 07:35 | 05:50 | 06:04 | 13:03 | 11:17 | 11:30 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 15:50 | 14:45 | 14:58 | 18:30 | 16:42 | 16:55 | 20:00 | 18:23 | 18:36 |
| 11 | Дш | 5 | 05:37 | 03:49 | 04:02 | 06:09 | 04:22 | 04:36 | 07:37 | 05:52 | 06:06 | 13:03 | 11:17 | 11:30 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 15:48 | 14:42 | 14:55 | 18:27 | 16:40 | 16:53 | 19:57 | 18:21 | 18:34 |
| 12 | Сш | 6 | 05:39 | 03:51 | 04:04 | 06:11 | 04:24 | 04:38 | 07:39 | 05:54 | 06:08 | 13:03 | 11:16 | 11:29 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 15:46 | 14:40 | 14:53 | 18:25 | 16:37 | 16:50 | 19:55 | 18:18 | 18:31 |
| 13 | Чш | 7 | 05:41 | 03:53 | 04:07 | 06:13 | 04:26 | 04:40 | 07:41 | 05:56 | 06:10 | 13:02 | 11:16 | 11:29 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 15:44 | 14:38 | 14:51 | 18:22 | 16:35 | 16:48 | 19:52 | 18:16 | 18:29 |
| 14 | Пж | 8 | 05:43 | 03:55 | 04:09 | 06:15 | 04:28 | 04:42 | 07:43 | 05:58 | 06:12 | 13:02 | 11:16 | 11:29 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 15:42 | 14:36 | 14:49 | 18:20 | 16:32 | 16:45 | 19:50 | 18:13 | 18:26 |
| 15 | Жм | 9 | 05:45 | 03:57 | 04:11 | 06:17 | 04:31 | 04:44 | 07:45 | 06:01 | 06:14 | 13:02 | 11:16 | 11:29 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 15:40 | 14:33 | 14:46 | 18:18 | 16:30 | 16:43 | 19:48 | 18:11 | 18:24 |
| 16 | Шм | 10 | 05:47 | 03:59 | 04:13 | 06:19 | 04:33 | 04:46 | 07:47 | 06:03 | 06:16 | 13:02 | 11:15 | 11:29 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 15:39 | 14:31 | 14:44 | 18:15 | 16:27 | 16:40 | 19:45 | 18:09 | 18:22 |
| 17 | Як | 11 | 05:49 | 04:01 | 04:15 | 06:21 | 04:35 | 04:48 | 07:49 | 06:05 | 06:18 | 13:01 | 11:15 | 11:28 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 15:37 | 14:29 | 14:42 | 18:13 | 16:25 | 16:38 | 19:43 | 18:06 | 18:19 |
| 18 | Дш | 12 | 05:51 | 04:03 | 04:17 | 06:23 | 04:37 | 04:50 | 07:51 | 06:07 | 06:20 | 13:01 | 11:15 | 11:28 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 15:35 | 14:27 | 14:40 | 18:10 | 16:22 | 16:35 | 19:40 | 18:04 | 18:17 |
| 19 | Сш | 13 | 05:53 | 04:05 | 04:18 | 06:25 | 04:39 | 04:52 | 07:53 | 06:09 | 06:22 | 13:01 | 11:15 | 11:28 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 15:33 | 14:25 | 14:38 | 18:08 | 16:20 | 16:33 | 19:38 | 18:02 | 18:15 |
| 20 | Чш | 14 | 05:55 | 04:07 | 04:20 | 06:27 | 04:41 | 04:54 | 07:55 | 06:11 | 06:24 | 13:01 | 11:15 | 11:28 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 15:31 | 14:22 | 14:35 | 18:06 | 16:18 | 16:31 | 19:36 | 17:59 | 18:12 |
| 21 | Пж | 15 | 05:57 | 04:09 | 04:22 | 06:29 | 04:43 | 04:56 | 07:57 | 06:13 | 06:26 | 13:01 | 11:15 | 11:28 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 15:30 | 14:20 | 14:33 | 18:04 | 16:15 | 16:28 | 19:34 | 17:57 | 18:10 |
| 22 | Жм | 16 | 05:59 | 04:11 | 04:24 | 06:31 | 04:45 | 04:58 | 07:59 | 06:15 | 06:28 | 13:01 | 11:14 | 11:27 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 15:28 | 14:18 | 14:31 | 18:01 | 16:13 | 16:26 | 19:31 | 17:55 | 18:08 |
| 23 | Шм | 17 | 06:01 | 04:13 | 04:26 | 06:33 | 04:47 | 05:00 | 08:01 | 06:17 | 06:30 | 13:00 | 11:14 | 11:27 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 15:26 | 14:16 | 14:29 | 17:59 | 16:11 | 16:24 | 19:29 | 17:53 | 18:06 |
| 24 | Як | 18 | 06:03 | 04:15 | 04:28 | 06:35 | 04:49 | 05:02 | 08:03 | 06:19 | 06:32 | 13:00 | 11:14 | 11:27 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 15:24 | 14:14 | 14:27 | 17:57 | 16:08 | 16:21 | 19:27 | 17:51 | 18:04 |
| 25 | Дш | 19 | 06:05 | 04:17 | 04:30 | 06:37 | 04:51 | 05:04 | 08:05 | 06:21 | 06:34 | 13:00 | 11:14 | 11:27 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 15:23 | 14:12 | 14:25 | 17:54 | 16:06 | 16:19 | 19:24 | 17:48 | 18:02 |
| 26 | Сш | 20 | 06:07 | 04:19 | 04:32 | 06:39 | 04:53 | 05:06 | 08:07 | 06:23 | 06:36 | 13:00 | 11:14 | 11:27 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 15:21 | 14:10 | 14:22 | 17:52 | 16:04 | 16:17 | 19:22 | 17:46 | 17:59 |
| 27 | Чш | 21 | 06:09 | 04:21 | 04:34 | 06:41 | 04:55 | 05:09 | 08:09 | 06:25 | 06:39 | 13:00 | 11:14 | 11:27 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 15:19 | 14:07 | 14:20 | 17:50 | 16:01 | 16:14 | 19:20 | 17:44 | 17:57 |
| 28 | Пж | 22 | 06:11 | 04:23 | 04:36 | 06:43 | 04:57 | 05:11 | 08:11 | 06:27 | 06:41 | 13:00 | 11:14 | 11:27 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 15:17 | 14:05 | 14:18 | 17:48 | 15:59 | 16:12 | 19:18 | 17:42 | 17:55 |
| 29 | Жм | 23 | 06:13 | 04:24 | 04:38 | 06:45 | 04:59 | 05:13 | 08:13 | 06:29 | 06:43 | 13:00 | 11:14 | 11:27 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 15:16 | 14:03 | 14:16 | 17:46 | 15:57 | 16:10 | 19:16 | 17:40 | 17:53 |
| 30 | Шм | 24 | 06:15 | 04:26 | 04:39 | 06:47 | 05:02 | 05:15 | 08:15 | 06:32 | 06:45 | 13:00 | 11:14 | 11:27 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 15:14 | 14:01 | 14:14 | 17:44 | 15:55 | 16:08 | 19:14 | 17:38 | 17:51 |
| 31 | Як | 25 | 06:17 | 04:28 | 04:41 | 06:49 | 05:04 | 05:17 | 08:17 | 06:34 | 06:47 | 13:00 | 11:13 | 11:27 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 15:12 | 13:59 | 14:12 | 17:42 | 15:52 | 16:05 | 19:12 | 17:36 | 17:50 |

*Балалар өчен*

**Фәйрүзә МӨСЛИМОВА**

## ТАТАР ӘЛИФБАСЫ

Рәсем ясадым, карагыз,
Төсле буяулар белән.
Зәңгәр һава, сары кояш,
Ал чәчәк, яшел үлән.



Нинди гүзәл безнең дөнья!
Аллаһ – бөек иҗатчы!
Рәсем төшергәндә, миңа
Ул – бердәнбер илһамчы!

*Саулыгым-байлыгым*

## МИЛӘШ



Миләш согын халык медицинасында атеросклерозны һәм гипертоник авыруларны дәвалау өчен файдаланалар. Миләш төнәтмәсе дизентерияне дәвалау өчен дә кулланыла. Ашказаны, эчәк авырулары вакытында аннан төнәтмә ясап эчәргә киңәш итәләр. Миләш согы бөердән ташларны чыгару өчен дә файдаланыла. Моның өчен 400г миләшне изәләр, аңа 2 литр кайнаган су һәм бераз шикәр комы салалар, дүрт сәгатьтән соң болгатып сөзәләр һәм эчәләр. Эч катканда берничә атна буена көнгә өч тапкыр 70-100 грамм шундый сок эчәргә киңәш ителә. Табиблар диабет белән авырганнарга, бавыры авырткannarга миләш ашарга куша. Азканлылык булганда мондый рецепт тәкъдим ителә: ике аш кашыгы кызыл миләш җимешен ике стакан кайнар суга салалар, бер сәгатьтән соң сөзәләр. Шуны көн буена өч-дүрт тапкыр аз-азлап эчәләр. Үт куыгы ялкынсынган (холецистит) кешеләр дә миләш согыннан файда күрәләр. Миләш кан басымын нормада тоту өчен дә кулланыла.

*Төзәтү*

*Алдагы санда газетаның чираттагы номеры 15 дип күрсәтелгән, 16 нчы номер дип кабул итәргә.*

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**
**Баш мөхәррир**
**Муллагалиева А. Г.**
**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Бу санның тиражы: 1100**
**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп, динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

**Нәшир, типография һәм редакция адресы:**
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча 16 сентябрь 16 сәг.**
**фактта 16 сентябрь 16 сәг.**
**Бәясе ирекле**